
Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының «Гомуми төрдәге 31 нче номерлы «Чишмә» балалар бакчасы» муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»




# Проект «Нур тарартучы рәсемнәр иясе» (4-7 мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен)

Әзерләде: 1 квалификацион категорияле тәрбияче - Зайнуллина Гузәл Тәлгат кызы

***Бакый Урманче – сынлы сәнгатьнең аксакалы.***
***Бездән татар поэзиясенә һәм музыкасына нигез салучылар кем дип сорасалар Тукай һәм Сәйдәш дибез.***
***Ә татар сынлы сәнгатенә кем күпер салган дисәләр, Бакый ага Урманче дип җавап бирәбез.***

***Нәкый Исәнбәт***



Һәр кешенең исеме булган кебек, урамның да үз атамасы бар. Ул исем аңа болай гына бирелмәгән. Ул ниндидер хәл, вакыйганы, йә булмаса ниндидер бөек эш эшләгән кешене мәңгеләштерү өчен куелган. Димәк, без дә урам исемнәренең тарихын белергә тиешбез.







Безнең 31 нче номеры “Чишмә” балалар бакчасының Бакый Урманче урамында урнашкан. Балалар бакчасы шундый атаклы шәхес урамында урнашуы белән мин бик горурланам һәм балаларны кечкенәдән үк үз халкының, үз туган җиренең, кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү, бик мөхим дип уйлыйм.







# Бакый Идрис улы Урманче



Бакый Идрис улы Урманче - нәкыш остасы, сынчы, график һәм педагог, Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы, республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Ул - татар сынлы сәнгатенә нигез салучы һәм үзе исән чагында ук классик дип танылган рәссам.


Кара Аккош













**Проектның максаты:**
Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар халкының бөек рәссамы - Бакый Урманче иҗаты белән таныштыруның әһәмиятен үстерү.
**Бурычлар:**
**Тәрбияви:** Бакый Урманченың күпкырлы иҗатына кызыксынучанлык, ихтирам хисләре тәрбияләү. Рәссам иҗаты белән таныштыру аша туган телгә мәхәббәт, үз милләтеңнең күренекле шәхесенә карата хөрмәт, горурлык хисләрен тәрбияләү.
**Үстерешле:** балаларны сәнгати-эстетик чынбарлыкның төрле төрләренә тарту, иҗади сәләтләрен ачу, сурәтләү ысулларын сайлап алу мөмкинлеге бирү, **б**әйләнешле грамматик яктан дөрес диологик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү, балаларга төрле темаларга, аларны кызыксындырган предметлар, табигать күренешләре турында татар телендә аралашуны активлаштыру. Рәсем ясау ысулларын ныгыту.
**Белем бирүче:** Балаларны татар халкының бөек шәхесе Бакый Урманче иҗаты белән таныштыру, рәссамның биоргафиясе, эшчәнлеге
һәм иҗат сәхифәләре турында белемнәрен баету.
**Проект дәвамлылыгы:** Озак вакытлы.
Проектта катнашучылар: балалар, эти-әниләр, тәрбиячеләр.

# Проектның актуальлеге:

Бүгенге көндә шәһәрдә яшәүче татар гаиләләрендә үз телендә иркен сөйләшүчеләр әз, чөнки күбесе бер-берсе белән рус телендә аралаша, җәмәгать урыннарында, транспортта, урамда да, рус телендә сөйләшә. Әлбәттә, балага туган тел иң беренче чиратта гаиләдә сеңдерелә. Гаиләдә, аннан соң балалар бакчасында туган телендә тәрбияләнгән бала ана телен инде онытмаячак, ди белгечләр. Аннан соң, ана телендә тәрбияләнгән бала тәртиплерәк, әхлаклырак, туган җанлырак та була. Безнең балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бала аңына үз халкының үсеш тарихын, мәдәниятен, милли үзенчәлекләрен, үз төбәгенең тарихы һәм күренекле шәхесләре турындагы мәгълүматны үз туган телендә сеңдергәндә генә анда үз милләтенә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләнә. Сынлы сәнгатькә эстетик кыйммәтләр арасында аерым урын бирелә - алар гамәлдәге һәм күптән юкка чыккан күренешләрне һәм табигать обектъларын, җәмгыятьне яңа буыннар өчен саклыйлар. Рәссамнарның картиналарын, репродукцияләрен карау балаларда мөстәкыйль фикер йөртә һәм сәнгать белән кабул итүне баета. Картиналарны караганда балаларның күргән образларга шәхси караш формалаша, кешеләрнең, табигать күренешләренең эмоциональ торышын аңларга этәрә. Рәссам иҗаты белән танышу, аның байлыгын һәм эчтәлеген күрсәтергә ярдәм итә, матурлык турындагы күзаллау формалаштыра.

“Нур таратучы рәсемнәр иясе” проекты балаларны, әти-әниләрне, тәрбиячеләрне аның иҗаты белән тирәнтен таныштыруга, кызыксынучанлык теләген уятуга юнәлдерелгән.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- Балаларда татар рәссам Бакый Урманче иҗатына карата кызыксыну һәм горурлык хисе уяту.
- Балаларда рәсем сәнгатенең төрләре турында күзаллау һәм аларны аера белү күнекмәләре булдыру.
- Матурлыкны күрә белергә, үз куллары белән гүзәллек тудырырга омтылып яшәү күнекмәләре булдыру

**Проект эшчәнлегенең продукты:** Бакый Урманченың иҗатына багышланган иҗади кичә "Илһам кайтавазы".

# Бакый Урманче иҗаты белән танышытыру буенча перспектив-тематик план

| № | Үткәрү вакыты | Тема | Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Әти-әниләр белән балаларның бердәм эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Ел дәвамында** | **“Туган илем”, “Туган шәһәрем”, “Шәһәр урамнары”, «Туган ягым - Яшел Үзән»** | **Әңгәмә үткәрү, фотосурәтләр карау, презентация карау.** | **Рәсемнәр ясау, рельефлы сүрәтләү техникасын кулланып шәһәрнең танылган урыннарын ясау.** | **Шәһәр урамнары буенча экскурсия. Танышу.** |
| 1. | Сентябрь | Рәссам һөнәре белән таныштыру. | Әңгәмә үткәрү, фотосурәтләр карау, презентация карау. | Сюжетлы-рольле уен «Рәссам остаханәсе” | Уен өчен кирәкле атрибутлар әзерләү. |
| 1. | Сентябрь | Рәссам Бакый Урманченың тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру. | Үстерелешле диалог, әңгәмә. | Рәсемнәр карау, сорауларга җавап бирү. | Рәссамның иҗатына кагылышлы материал туплау. |
| 2. | Сентябрь | Бакый Урманченың картиналары репродукцияләре күргәзмәсе оештыру | Күргәзмәдәге рәсемнәр белән якыннан танышу,картиналар карау | Күргәзмәдән калган хисләр буенча рәсем ясау. Рефлексия. | Казан шәһәрендә урнашкан Б. Урманче музеена бару. |
| 3. | Октябрь | “Б.Урманче иҗатында Габдулла Тукай образы” | Интегральләшкән эшчәнлек | Г. Тукай әсәрләре буенча әңгәмә һәм әвәләү. Габдулла Тукайның “Көз” шигырен уку. | Әти-әниләр белән әвәләү өчен материал әзерләү. |
| 4. | Ноябрь | “Бакый Урманче халык күңелендә” | Интегральләшкән эшчәнлек “Сирень” | Балалар белән тәэсирләр турында әңгәмә үткәрү. | |
| 6. | Ноябрь | “Бакый Урманче картиналарында табигать күренешләре” | Картиналар карау “Зәя буенда”, “Атлар коендыру”, “”Соңгы яфраклар”. | Төсле карандашлар ярдәмендә табигатьне сурәтләү. “Көз көне”, М.Мозаффаров муз., Н.Гайсин сүз. – аудиоязма тыңлау. | Әти-әниләр белән рәсем буяу өчен карандашлар әзерләү |
| 8. | Ноябрь | Балалар бакчасы холында БакыйУрманче иҗатына багышланган стенд урнаштыру. | “Чишмә” балалар бакчасының Бакый Урманче урамында урнашуы турында мәгълүмат бирү. Стенд янында балалар белән әңгәмә оештыру. | Балаларның бер-берсе белән фикер алышулары. | Стенд өчен яңа мәгълүмат туплау. |
| 7. | Ноябрь | “Салават күпере”. Танып белү | Эзләнү-тикшеренү эшчәнлеге. | Палитрада буяулар кушып җылы һәм | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Декабрь | Б. Урманче скульптуралары белән танышу | Сөембикә сыны сүрәтләнгән фото карау. Агачтан эшләнгән Шүрәле сыннары белән таныштыру. | Дидактик уен “Рәсем нинди жанрда ясалган?”<br>Тозлы камырдан сыннар әвәләү | “Әти-әниләр ярь” клубы утырышы “Б.Урманченың иҗат дөньясы” |
| 10. | Январь | Уеннар “Кисәкләрдән җый”, “Җанлы картина”“ (Алып баручы картинадагы бер объектны уйлый, ә балалар сораулар ярдәмендә аны таныырга тиеш) | Уеннарның кагыйдәрен аңлату | Балаларның уеннары | Әти - әниләр уеннар өчен рәсемнәр әзерләп куялар |
| 11. | Январь | “Бакый Урманченың виртуаль музее” | Онлайн видеоролик карау | Музей турында әңгәмә үткәрү, фикер алышу | Әти-әниләргә Бакый Урманче музеена экскурсиягә барырга тәкъдим итү |
| 12. | Февраль | “Бакый Урманченың тылсымлы сәнгать дөньясы” | Интегральләшкән эшчәнлек | | “Чишмә”журналын чыгару. |
| 13. | Февраль | Триптих “Татарстан” | Интегральләшкән эшчәнлек | Халык уены “Буяу сатыш” | Эш өчен кирәкле кулланмалар туплау |
| 14. | Март | Үстерешле мультфильм карау “Уроки тетушки Совы” | “Картиналар галлереясе әкияте” | Мультфильм караганнан соң әңгәмә үткәрү. | |
| 15. | Апрель | Рәссам портретлар галлереясы | “Яраткан әниемнең портреты” рәсем ясау. “Сара ханым улы Ильдар белән” картинасын карау | Портрет жанры белән танышу. Аудиоязма тыңлау “Әни кирәк”, М. Шәмсетдинова муз., Р. Миңнуллин сүзләре | “Әти-әниләр ярь”клубы утырышы. Әти-әниләрнең гаиләдәге иҗади-эстетик тәрбия бирү тәҗрибәсе белән уртаклашу. |
| 16. | Апрель | Бакый Урманче иҗатында Г.Тукайның “Шүрәлесе” | Баларны Б.Урманчы тудырган “Шүрәле” образы белән таныштыру | “Шүрәле” балетыннан өзек карау. | Рәсем ясау өчен карандашлар әзрләү. |
| 17. | Май | Рәссамның Советлар Союзы герое Гани Сафиуллинга багышланган картинасы белән танышу. | Балаларга Советлар Союзы герое Гани Сафиуллин турында сөйләү | Балалар белән 9 Май Җиңү көненә багышланган слайдлар карау, җырлар тыңлау | “Үлемсез полк” күргәзмәсе өчен сугышта катнашкан әби-бабайлар фотосүрәтләрен алып килү. |
| 18. | Май | «Бакый Урманченың балачагы». Театральләштерелгән әдәби-музыкаль композиция. | Булган мәгълүматларга таянып иҗат ителгән театральләшкән композиция. Танылган рәссамның балачагына кыскача сәяхәт. | Балаларның чарадан соң уй-фикерләре белән бүлешүләре. | Театральләшкән чара өчен атрибутлар туплау. |

# Әңгәмә, шөгыль, күргәзмә

Әңгәмәләр, шөгыльләр үткәрәм, күргәзмәләр оештырам. Без балалар белән картиналар, репродукцияләр карыйбыз, фикер алышабыз. Картиналарны караганда балаларның күргән образларга шәхси караш формалаша, кешеләрнең күренешләренең эмоциональ торышын аңларга этәрә, туган як матурлыгына соклану хисе тәрбияләнә.
















Габдулла Тукай
Шүрәле










Бакый Урманченың “Сирень” картинасы
буенча шөгыль.







Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләп килүче “Ак калфак” оешмасының күчмә утырышы. “Халкыбызның көче-аның атаклы кешеләрендә, милләттәшләребездә” дип исемләнгән җыен Яшел Үзәннең “Чишмә” балалар бакчасында.













Безнең бакчабызда тәрбияләнүче балаларның рәсемнәре “Салават күпере” журналында басылып тора. Балалар “Тылсымлы рәсем” онлайн дәресләрендә дә бик актив катнашалар.

# Бакчабызда музей педагогикасы.











# Казан шәһәренең Бакый Урманче музее







Балалар бакчасы тәрбиячеләре белән Казан шәһәрендәге Бакый Урманче музеена бардык. Музейда безне күп нәрсәләр тәэсирләндерде. Аерым картиналар күңелгә кереп калды.








# Яшел үзән шәһәренең балалар сәнгать мәктәбенә картиналар күргәзмәсенә экскурсия

Әти-әниләр балалар белән берлектә Яшел Үзән шәһәренең балалар сәнгать мәктәбенә картиналар күргәзмәсенә экскурсия кызыклы һәм файдалы чара булып тора. Россия һәм Татарстан рәссамнар берлеге әгъзасы Новиков Владимир Николаевич балаларга Бакый Урманче иҗаты турында сөйләде, үз картиналары белән танышытырды. Картиналарны якыннан күрү балалар өчен ачыш булды, күңелләрендә онытылмас хис калдырды.







**Татарстанның Арча муниципаль районы Габдулла Тукай мемориаль комплексында**









Музей комплексы бинасы Бакый Урманче проекты буенча төзелгән. Бакый Урманче үз иҗатында бигрәк тә Тукай әсәрләрен үзәк урынга куя. Бакый Урманченың агачтан эшләнгән 4 метрлы Шүрәлеләре гаҗәпкә калдырды. Музейдан без бик күтәренке хисләр белән кайттык.





# Бакый Урманче ижатына багышылынган стенд һәм рәссамның картиналары репродукцияләреннән күргәзмә












# Бакый Урманченең тормыш юлы

Рәссам белән таныштыруның иң уңышлы алымнарның берсе ул “Кечкенә Бакыйның тормышы” дип аталган театральләштерелгән музыкаль композиция. Бу композицияне карагач, балалар Урманчеларның гаилә атмосферасын тоеп, шул чор көйләрен тыңлап, рәссамның балачагына кайткандай булдылар. Бу алым аңлаешлы, истә калырлык.









# “Нур таратучы рәсемнәр иясе”









Рәссамның ижатына кызыксыну уяту максатыннанн балалар бакчасында “Нур таратучы рәсемнәр иясе” дип атал картиналар бәйгесен үткәрдек. Әти-әниләр һәм балалар бик теләп катнаштылар.









***Халык әйтә: “Гомер бакый,” – диеп,***
***“Бакый” сүзе ул бит мәңгелек.***
***Бакый, Бакый… Даһи кешебезгә***
***Кушканнар бит аны бик белеп.***

